КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 сентябрь г.Казань № 782

2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты хакында

2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турындагы, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты хакындагы докладларны тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын хупларга.

2. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2024 елның 4 октябренә кадәр «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына 2024 елның 4 октябренә кадәр «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин